ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                                    КАРАР

_______________                с. Верхний Услон                _______________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы чикләре авыл җирлекләре арасында автомобиль транспортында даими пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 16 августындагы 1096 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 480-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Нигезләмәнең 5.2 п. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   «Җайга салынмый торган тариф кулланып, муниципаль маршрут буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык алу хокукына ачык конкурс оештыру өчен түбәндәгеләр нигез була:
   а) яңа муниципаль маршрут билгеләү;
   б) 220-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 1 нче пунктында каралган нигезләрдә регуляр пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуын туктату;
   в) 220-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә әлеге маршрутка карата җайга салынулы тарифлар буенча даими пассажирлар йөртүне туктату һәм җайга салынмый торган тарифлар буенча даими ташуларны гамәлгә ашыра башлау турында карар кабул ителгән очракта;
   г) 220-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 12 ст. 3.1 ө. яки 8 ө. 8 өлешендә каралган срокларда юридик зат, хосусый эшмәкәр яки гади ширкәт килешүендә катнашучы алдан бирелгән таныклыкларны һәм әлеге маршрут карталарын киләсе срокка озайту турында гариза белән җирле үзидарәнең вәкаләтле органына мөрәҗәгать итмәгән очракта әлеге маршрутны үзгәртү турында карар».
2. Нигезләмәнең 5 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 5.2.1 пункт өстәргә:

«Ачык конкурсны үткәрмичә, муниципаль маршрут буенча даими пассажирлар ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут картасы даими пассажирлар йөртү өчен билгеләнгән очракта бирелә:

- 220-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 1 өлешендә 1,2 яки 7 пунктында каралган шартлар килеп җиткәннән соң һәм регуляр рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча ачык конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча бирелгән яңа таныклык нигезендә даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында Яңа таныклык нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртә башлаганчыга кадәр».

3. Нигезләмәнең 5.3 п. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   «Ачык конкурс уздыру тәртибе, ачык конкурста катнашучыларга таләпләр, заявкаларны бәяләү һәм чагыштыру критерийлары 220-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнә».
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм бастырды
О.А.Сельская